Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая, д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

2026 елның 28 нче июленнән № 33

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Камай авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»03.06.2014 елгы 14 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Биш көн эчендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның күрсәтелгән схемасын Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга.

4. Әлеге карарны "http://pravo.tatarstan.ru/" Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм "http://mendeleevsk.tatarstan.ru/" Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.М.Ахунҗанов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге башкарма
комитетының 2026 елның 28
июлендәге 33 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объектларының урнашу урыны исеме | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектлары тибы (павильон, киоск, автомагазин, автолавка, тонар, лоток контейнер, бакча разваллары) | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалануы | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Камай авылы, Дифгать Сирай урамы , 29 а йорты (КФҮ янында) | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар | автолавка , палаткалар, лотоклар | кулланыла | Ел әйләнәсе |
| 2 | Мәйдан (сабантуй бәйрәмен үткәрү мәйданчыгы) | Балалар уенчыклары, кондитер эшләнмәләре, азык-төлек товарлар | палаткалар | кулланыла | бәйрәм чаралары, елга бер тапкыр июнь аенда |